ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә медицина таныклавын үткәрергә вәкаләтле медицина оешмалары исемлеген билгеләү.»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге статьяның 1 өлешендәге уналтынчы абзацында күрсәтелгән вәкаләт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.»;

2) 5 статьяның 3 өлешендә:

а) беренче абзацта «профилактик» сүзен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина тикшерүләре уздыру, хисаплылык алып бару, шәхси медицина кенәгәләрен, шул исәптән электрон документ рәвешендә, исәпкә алу һәм аларны хезмәткәрләргә бирү тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2021 елның 31 октябрендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 64-ТРЗ